**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статью 6 Закона Республики Татарстан «Об инвестиционной деятельности в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
29 марта 2024 года

**Статья 1**

Внести в статью 6 Закона Республики Татарстан от 25 ноября 1998 года № 1872 «Об инвестиционной деятельности в Республике Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 19 ноября 2020 года № 72-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 1998, № 12; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2020, № 87 (часть I); 2021, № 93 (часть I); 2022, № 77 (часть I); 2023, № 20 (часть I), № 73 (часть I) следующие изменения:

1) в пункте 3 части 1 слова «и инвестиционных проектов на объекты государственной собственности Республики Татарстан» заменить словами «и иных инвестиционных проектов»;

2) в части 2 слова «, предусмотренных законодательством о государственно-частном партнерстве, муниципально-частном партнерстве, о концессионных соглашениях, о промышленной политике, об особых экономических зонах, о территориях опережающего развития» заменить словами «в соответствии с законодательством Российской Федерации».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль
12 апреля 2024 года
№ 12-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 29 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (2020 елның 19 ноябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 12; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешнең 3 пунктында «һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге объектларга инвестиция проектларын» сүзләрен «һәм башка инвестиция проектларын» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 өлештә «дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык, концессия килешүләре, сәнәгать сәясәте, махсус икътисадый зоналар һәм социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләр турындагы законнарда каралган» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарында каралган» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ ГОМУМИ БУЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ АДМИНИСТРАЦИИ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казань, Кремль
2024 ел,12 апрель
№ 12-ТРЗ